**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
**М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190**

**тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 2-28** **от «19» ноября 2018 г.**

2019 елга һәм 2020 һәм 2021
елларның планлы чорына Мамадыш
муниципаль районы Мамадыш
шәһәре бюджеты проекты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Мамадыш шәһәре Уставының 92 статьясына һәм Мамадыш муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы к а р а р к а б у л и т т е:

1. 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре бюджеты проектын беренче укылышта кабул итәргә (1 нче кушымта).

2. Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәренең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты проектын, Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәренең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен, шулай ук фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында фикер алышуларда катнашу тәртибен «Нократ» («Вятка») район газетасында бастырып чыгарырга. (2 нче кушымта).

3. 2019 елга, 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре бюджеты проекты буенча ачык тыңлауларны 2018 елның 10 декабренә 9 сәгатьтә Мамадыш муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының утырышлар залында билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш шәһәре Советының бюджет, икътисадый сәясәт һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш шәһәре башлыгы,
шәһәр Советы рәисе А.П.Иванов

Мамадыш
муниципаль районы
Мамадыш шәһәре Советының
2018елның 19 ноябрендә кабул ителгән
«2019 елга һәм 2020 һәм 2021
елларның планлы чорына Мамадыш
муниципаль районы Мамадыш
шәһәре бюджеты проекты турында»
№ 2-28 карарына 2 нче кушымта

Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Мамадыш ш., М. Җәлил ур., 23/33 йорт, каб.110, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru яисә 3-24-00 номерына факс буенча, эш көннәрендә 9.00 – 17.00 сәгатьләрдә, карар «Нократ» («Вятка») район газетасында басылып чыккан көннән башлап, язма рәвештә, кушымтада бирелгән үрнәк нигезендә, төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| № | Пункт | Бюджет проекты тексты | авторның проекты тексты | проекты тексты төзәтмәләрне исәпкә алып | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш яки уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: Мамадыш ш., М. Җәлил ур., 23/33 йорт, шәхсән, почта аша  ул. М. Джалиля, дом 23/33 лично, по почте (конвертта «бюджет проекты турында фикер алышу» яки «ачык тыңлаулар» тамгасы белән), e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru яисә 3-24-00 номерына факс буенча 2018 елның 9 декабренә кадәр.

3. Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре башкарма комитетына 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре бюджеты проекты буенча билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарның билгеләнгән срокларда ачык тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга.

Мамадыш шәһәре башлыгы
урынбасары А.Х.Аглямов